ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь, 2025 ел № 2/5

Шәһәр Советының 2021 елның 27 декабрендәге 11/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең җирле узидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларны мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Яр Чаллы шәһәре шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 48.1 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган муниципаль хокукый актлар системасы турында Нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2021 елның 27 декабрендәге 11/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең җирле узидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларны мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Иминләштерелгән затларга (файда күрүчеләргә) түләнә торган иминият суммалары күләме муниципаль вазыйфаны биләүче затның айлык акчалата бүләкләренә (алга таба ─ бүләкләү)1,2 коэффициенты кулланып билгеләнә.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 8.1 пункт өстәргә:

«8.1. Иминият суммасын исәплəгәндә биләгән муниципаль вазыйфа буенча иминият очрагы башланган көнгә, аның артуын (индексациясен) исәпкә алып, билгеләнгән түләү исәпкә алына.».

2. Әлеге Карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев